СОВЕТ СРЕДНЕКИРМЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Ленина, д.16А, с. Средние Кирмени, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422171

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРТА КИРМӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Ленин ур., 16А нчы йорт, Урта Кирмән авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422171

тел.(факс): (85563) 2-92-38;2-92-44 e-mail: Skimer.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение Карар

№ 2-22 20 февраль 2023 ел

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге Советының 2018 елның 05 июнендәге № 1-31 карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирлеүзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Территорияләрнең комплекслы үсешен тәэмин итү максатларында Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»2020 елның 30 декабрендәге №494-ФЗ Федераль закон, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Урта Кирмән авыл җирлеге Советы **карар кабул итте**:

1.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге Советының 2018 елның 05 июнендәге«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районыныңУрта Кирмән авыл җирлеге муниципаль берәмлегендәгавамитыңлаулар (иҗтимагыйфикералышулар) оештыруһәмуздырутәртибе турында»1-31 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.Кушымтаның 12 статьядагы 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 28 статьясындагы 3 пунктының 3.1 һәм 3.2 өлешләрендә билгеләнгән очраклардан тыш, җирлекләрнең генераль планнары проектлары һәм җирлекләрнең генераль планнарына үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар буенча иҗтимагый фикер алышулар яки гавами тыңлаулар муниципаль берәмлекнең һәр торак пунктында үткәрелә».

1.2. Кушымтаның 12 статьясындагы 2 абзацындагы«, шәһәр округы генераль планнары» сүзләрен төшереп калдырырыга.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының (pravo.tatarstan.ru) рәсми порталында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге башлыгы Б.Ф.Хасановка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Урта Кирмән авыл җирлеге
Советы рәисе, җирлек башлыгы Б.Ф.Хасанов